| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

18 декабря 2023г. с.Шалты № 84

Шалты авыл җирлегенең 2024 елга
һәм 2025 һәм 2026 еллар план
чорына бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1 нче статья

1. Шалты авыл җирлеге бюджетының 2024 елга төп характеристикаларын расларга:

1) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 4481,0 мең сум;

2) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгым күләме 4481,0 мең сум;

3) Шалты авыл җирлеге бюджет дефицитының гомуми күләме 0 мең сум.

2. Шалты авыл җирлеге бюджетының 2025 һәм 2026 елларга төп характеристикаларын расларга:

1) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 2025 елга 4539,3 мең сум һәм 2026 елга 4600,7 мең сум;

2) Шалты авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгым күләме 2025 елга 4539,3 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган 109,3 мең сум күләмендә чыгымнар, һәм 2026 елга 4600,7 мең сум, шул исәптән шартлы

рәвештә расланган 220,8 мең сум күләмендә чыгымнар;

3) Шалты авыл җирлеге бюджет дефицитының гомуми күләме 2025 елга 0 мең сум һәм 2026 елга 0 мең сум.

3. 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Шәле авыл җирлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 нче статья

1. 2025 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә муниципаль эчке бурычның югары чиген расларга.

2. 2026 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә муниципаль эчке бурычның югары чиген расларга.

3. 2027 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә муниципаль эчке бурычның югары чиген расларга.

3 нче статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 нче статья

1. 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Шалты авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Шалты авыл җирлеге бюджеты чыгымнарын классификацияләү чыгымнары төрләренең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга.

3. Шалты авыл җирлеге бюджетының 2024 елга 0 мең сумлык, 2025 елга 0 мең сумлык, 2026 елга 0 мең сумлык җәмәгать норматив йөкләмәләрен үтәүгә

бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга.

5 нче статья

1. Җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен 2024 елга, 2101,2 мең сум күләмендә җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итү буенча төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга расларга 2101,2 мең сум, 2026 елга 2101,2 мең сум.

2. 2024 елда Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

6 нчы статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында Баулы муниципаль районы бюджетыннан 2024 елда бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 1654,5 мең сум, 2025 елда 1694,4 мең сум, 2026 елда 1735,7 мең сум күләмендә алынган дотацияләрне исәпкә алырга.

7 нче статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында 2024 елда җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәп-хисапны гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына Баулы муниципаль районы бюджетыннан алынган субвенцияләрне исәпкә алырга 152,5 мең сум, 2025 елда 167,9 мең сум, 2026 елда 184,0 мең сум.

8 нче статья

Шалты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2024 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

9 нчы статья

2024 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджеты акчаларының калдыклары 2023 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә

Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән муниципаль контрактларга түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыклары суммасыннан артмаган күләмдә, 2024 елда Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

10 нчы статья

Татарстан Республикасы Баулы районының Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты территориаль бүлеге төзелгән килешүләргә ярашлы рәвештә Шалты авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

11 нче статья

Әлеге карарны мәгълүмат стендында игълан итәргә һәм Шалты авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

12 нче статья

Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе — Фаткуллин З.Х.